**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 30 март № 196

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2015 елларда эш бирүчегә эш белән тәэмин ителмәгән инвалидны эшкә урнаштыру өчен эш урынын (шул исәптән махсус) җиһазландыру (җайлаштыру), инвалидларның, шул исәптән кресло-коляскадан файдалана торган инвалидларның, эш урыннарына тоткарлыксыз керә алуы өчен кирәкле инфраструктура булдыру чыгымнарын каплау тәртибен раслау турында» 2014 ел, 29 октябрь, 795 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Эш белән тәэмин ителмәгән инвалидларны эшкә урнаштыруда булышлык күрсәтү өлешендә халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә өстәмә чаралар тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2015 елларда эш бирүчегә эш белән тәэмин ителмәгән инвалидны эшкә урнаштыру өчен эш урынын (шул исәптән махсус) җиһазландыру (җайлаштыру), инвалидларның, шул исәптән кресло-коляскадан файдалана торган инвалидларның, эш урыннарына тоткарлыксыз керә алуы өчен кирәкле инфраструктура булдыру чыгымнарын каплау тәртибен раслау турында» 2014 ел, 29 октябрь, 795 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2015 – 2020 елларда эш бирүчегә эш белән тәэмин ителмәгән инвалид өчен эш урынын җиһазландыру (җайлаштыру) чыгымнарын каплау тәртибен раслау турында»;

1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. 2015 – 2020 елларда эш бирүчегә эш белән тәэмин ителмәгән инвалид өчен эш урынын җиһазландыру (җайлаштыру) чыгымнарын каплау тәртибен (каларга теркәлә) расларга.»;

әлеге карар белән расланган 2014 – 2015 елларда эш бирүчегә эш белән тәэмин ителмәгән инвалидны эшкә урнаштыру өчен эш урынын (шул исәптән махсус) җиһазландыру (җайлаштыру), инвалидларның, шул исәптән кресло-коляскадан файдалана торган инвалидларның, эш урыннарына тоткарлыксыз керә алуы өчен кирәкле инфраструктура булдыру чыгымнарын каплау тәртибен яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлә).

2. Бу карарның гамәле 2015 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2015\196.doc

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2014 ел, 29 октябрь, 795 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 30 март, 196 нчы
карары редакциясендә)

2015 – 2020 елларда эш бирүчегә эш белән тәэмин ителмәгән инвалид өчен эш урынын җиһазландыру (җайлаштыру) чыгымнарын каплау тәртибе

1. Гомуми нигезләмәләр

1. 2015 – 2020 елларда эш бирүчегә эш белән тәэмин ителмәгән инвалидны эшкә урнаштыру өчен эш урынын җиһазландыру (җайлаштыру) чыгымнарын каплау тәртибе (алга таба – Тәртип) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2015 елда «Халыкны эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү» Россия Федерациясе дәүләт программасының «Халыкны эш белән тәэмин итүдә актив сәясәт һәм эшсез гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү» ярдәмче программасы кысаларында федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында» 2014 ел, 20 декабрь, 1432 нче карары (алга таба – халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендәге өстәмә чаралар) һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 9 август, 553 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» дәүләт программасын тормышка ашыру максатларында эшләнде.

2. Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр эш белән тәэмин ителмәгән инвалидларны алар өчен җиһазландырылган (җайлаштырылган) эш урыннарына эшкә урнаштыруда булышлык күрсәтү максатларында халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендәге өстәмә чараларны тормышка ашыру өчен бирелә.

3. Тәртип эш бирүчегә 2015 – 2020 елларда эш белән тәэмин ителмәгән инвалидны эшкә урнаштыру өчен эш урынын җиһазландыру (җайлаштыру) чыгымнарын каплау механизмын, күләмен һәм шартларын билгели.

4. Инвалидны эшкә урнаштыру өчен җиһазландырыла (җайлаштырыла) торган эш урыны – инвалидларның индивидуаль мөмкинлекләрен исәпкә алып, төп һәм ярдәмче җиһазларны, техник һәм оештыру җиһазларын, өстәмә җиһазларны адаптацияләүне һәм техник җайланмалар белән тәэмин итүне кертеп, хезмәтне оештыру буенча өстәмә чаралар таләп итә торган эш урыны (алга таба – эш урыны).

5. Эш белән тәэмин ителмәгән инвалидлар өчен эш урыннарын җиһазландыруны (җайлаштыруны) эш бирүчеләр, инвалидларның бозылган

функцияләрен һәм яшәешләрендәге һәм эшчәнлекләрендәге чикләнүләрне, әлеге эш урыннарын мондый җиһазландыруга (җайлаштыруга) карата хезмәт һәм халыкны социаль яклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм тормышка ашыру һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы билгеләгән төп таләпләр нигезендә инвалидның һөнәрен (белгечлеген), башкарыла торган эшләрнең характерын, инвалидның эшкә сәләтен югалту дәрәҗәсен, эш урынының махсуслашу дәрәҗәсен, җитештерү процессының механикалаштырылуын һәм автоматлаштырылуын исәпкә алып гамәлгә ашыра.

6. Эш белән тәэмин ителмәгән инвалидларны җиһазландырылган (җайлаштырылган) эш урыннарына эшкә урнаштыру теләсә кайсы оештыру-хокук рәвешендәге һәм милек рәвешендәге оешмаларда, индивидуаль эшмәкәрләрдә, крестьян (фермер) хуҗалыкларында (алга таба – эш бирүче) гамәлгә ашырыла.

## II. Эш бирүчегә эш белән тәэмин ителмәгән инвалидны эшкә урнаштыру өчен эш урынын җиһазландыру (җайлаштыру) чыгымнарын каплау күләме, механизмы һәм шартлары

7. Эш бирүчегә эш белән тәэмин ителмәгән инвалидны эшкә урнаштыру өчен эш урынын җиһазландыру (җайлаштыру) чыгымнарын каплау халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендәге өстәмә чараларны тормышка ашыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган субсидияләр һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән башкарыла.

8. Эш бирүчегә эш белән тәэмин ителмәгән инвалидны эшкә урнаштыру өчен эш урынын җиһазландыру (җайлаштыру) чыгымнары бер даими эш урыны өчен 72,69 мең сумга тигез күләмдә каплана.

9. Түбәндәге чыгымнар капланырга тиеш:

эш урынын җиһазландыру (җайлаштыру) өчен кирәкле махсус җиһазлар, техник һәм тавыш изоляцияләү җайланмаларын (визуаль, акустика, тактиль) кертеп, җиһазлар сатып алу, монтажлау һәм кую;

махсус аудиопрограммалар, тавыш көчәйткеч махсус җиһазлар, махсус программа продукты, техник җайланмалар, начар күрүче һәм сукырлар, начар ишетүче инвалидлар өчен эш урынын җиһазландыру (җайлаштыру) өчен башка ярдәмче җиһазлар сатып алу.

10. Эш бирүче билгеләнгән квота хисабына эш урыннары, шулай ук эшсез инвалидлар өчен, Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 310 - 312 статьялары нигезендә өйдәге хезмәтне рәсмиләштереп, өйдә эш урыннары җиһазландыра (җайлаштыра) ала.

Эш урыны билгеләнгән квота хисабына җиһазландырылганда (җайлаштырылганда) бу Тәртипнең 9 нчы пунктында билгеләнгән эш урынын җиһазландыру (җайлаштыру) чыгымнары капланырга, ә булдырылган махсус эш урыны өчен аның чыгымнары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Инвалидларны эшкә урнаштыру максатында махсус эш урыннары булдыру өчен эш бирүчеләр чыгымнарын компенсацияләү тәртибен раслау турында» 2007 ел, 5 февраль, 32 нче карарында күздә тотылган тәртиптә каплана.

11. Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән эш бирүче агымдагы елның 20 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасындагы халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенең үз эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны буенча дәүләт учреждениесенә (алга таба – эш белән тәэмин итү үзәге) эш белән тәэмин ителмәгән инвалидларны эшкә урнаштыруда булышлык күрсәтүне үз эченә алган халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендәге өстәмә чараларны тормышка ашыруда катнашу өчен ирекле рәвештә язылган гариза (алга таба – гариза) җибәрә.

12. Гаризага, эш белән тәэмин ителмәгән инвалидны эшкә урнаштыру өчен эш урынын җиһазландыру (җайлаштыру) датасын һәм кыйммәтен күрсәтеп, эш урынын (шул исәптән өйдәге эш урынын) җиһазландыру (җайлаштыру) чыгымнарын күздә тота торган нигезләү теркәлә.

Шулай ук эш бирүче гаризага үз теләге буенча гариза җибәрелгән көн хәленә карата түбәндәге мәгълүматларны теркәргә хокуклы:

эш бирүченең бетерелү һәм бөлгенлек стадиясендә булмавы, мөлкәтенә һәм акчасына арест салынмау турында;

эш бирүченең теләсә кайсы дәрәҗәдәге бюджетларга яки бюджеттан тыш дәүләт фондларына исәпләнгән салымнар, җыемнар һәм мәҗбүри башка түләүләр буенча бурычлары булмау турында.

13. Эш бирүче бу Тәртипнең 12 нче пунктындагы өченче һәм дүртенче абзацларда күрсәтелгән документларны кертмәгән очракта, эш белән тәэмин итү үзәге әлеге документларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү тәртибендә соратып ала.

14. Эш бирүчеләрнең гаризаларын карау максатларыннан чыгып, эш белән тәэмин итү үзәге каршында составына эш белән тәэмин итү үзәге җитәкчесе һәм белгечләре, шулай ук муниципаль район (шәһәр округы) башкарма комитеты, инвалидлар җәмгыятьләре һәм башка оешмалар вәкилләре кертелә торган комиссия төзелә.

15. Гаризаны комиссия ул теркәлгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә карый. Гариза эш белән тәэмин итү үзәгенә кергән көнендә теркәлә.

Комиссия утырышы, аның исемлек буенча составының кимендә икедән өч өлеше булса, хокуклы була. Комиссия карары ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә һәм, аның өчен комиссиянең утырышта катнашучы әгъзаларыннан 50 процентыннан артыгы тавыш бирсә, кабул ителгән булып санала. Тавышлар тигез булса, рәислек итүче (комиссия рәисе яки аның урынбасары) тавышы хәлиткеч була.

16. Комиссия гаризаны карау йомгаклары буенча эш белән тәэмин ителмәгән инвалидны эшкә урнаштыру өчен эш урынын җиһазландыру (җайлаштыру) чыгымнарын каплау турында шартнамә (алга таба – Шартнамә) төзүнең максатка ярашлы булуы (максатка ярашлы булмавы) турында тәкъдимнамә рәвешендә карар чыгара.

Карар эш бирүче игътибарына мондый карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 3 көн эчендә җиткерелә.

17. Шартнамә төзүнең максатка ярашлы булуы турында тәкъдимнамә рәвешендә карар кабул ителә торган эш бирүчене билгеләү критерийлары булып түбәндәгеләр тора:

ул шундый ук һөнәрләр буенча эш башкарганда йә шундый ук эшне башкарганда башка эш бирүчеләр белән чагыштырганда хезмәт өчен түләүнең югарырак дәрәҗәсен тәкъдим итү;

җиһазландырыла (җайлаштырыла) торган эш урыннары (шул исәптән өйдәге) саны.

Моның белән бергә, әлеге карарны кабул итү шартлары булып түбәндәгеләр тора:

эш бирүченең барлык дәрәҗәдәге бюджетларга һәм бюджеттан тыш фондларга салымнар һәм җыемнар түләү буенча бурычларын үтәве;

юридик зат (оешма) булган эш бирүчегә карата бетерү яки бөлгенлек процедуралары үткәрелмәү.

18. Комиссиянең тәкъдимнамәләре уңай булганда эш белән тәэмин итү үзәге һәм эш белән тәэмин ителмәгән инвалидны эшкә урнаштыру өчен эш урынын җиһазландыруга (җайлаштыруга) гариза биргән эш бирүче арасында эш көннәрендә исәпләнә торган 7 көн эчендә Шартнамә төзелә. Шартнамәнең бертип формасы Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан раслана.

Шартнамәдә эш бирүчегә эш урынын җиһазландыру (җайлаштыру) чыгымнарын каплауга акча күчерү күләме, тәртибе, вакытлары, эш бирүченең эш урынын җиһазландыру (җайлаштыру) өчен алынган акчаны кире кайтару шартлары, тәртибе һәм вакытлары, шулай ук эш бирүчегә эш урынын җиһазландыру (җайлаштыру) чыгымнарын каплау өчен Тәртип һәм төзелә торган Шартнамә шартлары нигезендә алынган акчаны кире кайтару шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешенә Министрлык һәм Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы тарафыннан тикшерүләр гамәлгә ашыруга эш бирүченең ризалыгы күздә тотыла.

19. Эш бирүчегә эш урынын җиһазландыру (җайлаштыру) чыгымнарын каплау өчен акча күчерү бу Тәртиптә һәм Шартнамәдә күздә тотылган шартларда эш белән тәэмин итү үзәге тарафыннан башкарыла.

20. Эш бирүче эш урынын җиһазландыру (җайлаштыру) чыгымнарын каплау өчен, агымдагы елның 20 декабреннән дә соңга калмыйча эш белән тәэмин итү үзәгенә түбәндәгеләр белән бергә гариза кертә:

эш бирүченең күрсәтелгән чараларга токкан чыгымнарын раслый торган документлар күчермәләрен, шул исәптән башкарылган эшләрне (күрсәтелгән хезмәтләрне) кабул итү актлары, исәп-фактуралар, түләү йөкләмәләре, җиһазлар сатып алу йөкнамәләрнең эш бирүче мөһере белән таныкланган күчермәләрен теркәп, эш белән тәэмин ителмәгән инвалид өчен эш урынын җиһазландыру (җайлаштыру) турында эш бирүче кул куйган акт (алга таба – акт);

җиһазландырылган (җайлаштырылган) эш урынына кабул ителгән эш белән тәэмин ителмәгән инвалид белән төзелгән хезмәт шартнамәсенең эш белән тәэмин ителмәгән инвалидны эшкә кабул итү турындагы боерыкның эш бирүче тарафыннан таныкланган күчермәләрен.

Эш белән тәэмин итү үзәге эш бирүче акт керткән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә, комиссиянең кимендә ике әгъзасын җәлеп итеп,

аны карый һәм, каршы фикерләр булмаса, кул куя йә күрсәтелгән вакытта, нигезләп, баш тартуы турында хәбәр җибәрә.

21. Эш белән тәэмин итү үзәге үз исәбенә акча кергәннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган 7 көн эчендә акт нигезендә эш белән тәэмин ителмәгән инвалидны эшкә урнаштыру өчен эш урынын җиһазландыру (җайлаштыру) чыгымнарын каплау өчен эш бирүче исәбенә акча күчерә.

22. Эш бирүчегә эш белән тәэмин ителмәгән инвалидны эшкә урнаштыру өчен эш урынын җиһазландыруның (җайлаштыруның) бу Тәртиптә күздә тотылган чыгымнарын каплау, әгәр бу Тәртипнең 20 нче пунктында билгеләнгән документлар 20 декабрьдән дә соңга калмыйча кертелсә һәм эш бирүче бу Тәртиптә һәм Шартнамәдә каралган барлык шартларны үтәсә, гамәлгә ашырыла.

23. Эш белән тәэмин ителмәгән инвалидны эшкә урнаштыру өчен җиһазландырылачак (җайлаштырылачак) эш урыны вакытлыча характердагы эш урыны булмаска тиеш.

## III. Эш бирүчегә эш белән тәэмин ителмәгән инвалидны эшкә урнаштыру өчен эш урынын җиһазландыру (җайлаштыру) чыгымнарын каплау чыгымнарын финанслау тәртибе

24. Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән (алга таба – Федераль казначылык идарәсе) федераль бюджеттан акча керү турында мәгълүмат алганнан соң эш көннәрендә исәпләнә торган 15 көн эчендә акчаны Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы шәхси исәбеннән Министрлыкка күчерү өчен Федераль казначылык идарәсенә чыгымнар расписаниесен кертә.

25. Министрлык акча Министрлыкның шәхси исәбенә керү турында Федераль казначылык идарәсеннән алган чыгарма нигезендә акчаны Министрлык билгеләгән лимитлар нигезендә эш белән тәэмин итү үзәкләре исәпләренә күчерә.

26. Эш бирүчегә эш белән тәэмин ителмәгән инвалидны эшкә урнаштыру өчен эш урынын җиһазландыру (җайлаштыру) чыгымнарын каплау буенча чыгымнарны Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслау тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетында бу максатларга күздә тотылган акча күләмнәре нигезендә Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.

27. Министрлык акчаны тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетында күздә тотылган акча чикләрендә Министрлык билгеләгән лимитлар нигезендә эш белән тәэмин итү үзәкләре исәпләренә күчерә.

28. Министрлык квартал саен, хисап кварталыннан соң килүче айның 15 еннән дә соңга калмыйча, Хезмәт һәм эш белән тәэмин итү федераль хезмәтенә һәм Татарстан Республикасының Финанс министрлыгына финанслар белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын гамәлгә ашыру турында һәм эш белән тәэмин ителмәгән инвалидларны эшкә урнаштыруга булышлык күрсәтү өчен субсидия бирүнең нәтиҗәлелеге буенча максатчан күрсәткечләр мәгънәләренә ирешү хакында хисап кертә.

29. Күрсәтелгән акчаның агымдагы елның 1 гыйнварына файдаланылмый калган өлеше гамәлдәге законнарда күздә тотылган тәртиптә һәм очракларда федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты керемнә кире кайтарылырга тиеш.

## IV. Йомгаклау нигезләмәләре

30. Министрлык һәм Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы эш белән тәэмин ителмәгән инвалидны эшкә урнаштыру өчен эш урынын җиһазландыру (җайлаштыру) чыгымнарын каплау өчен бүлеп бирелгән бюджет акчасын бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүгә законнарда билгеләнгән тәртиптә тикшерү гамәлгә ашыра.

31. Эш белән тәэмин ителмәгән инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннарын җиһазландыру (җайлаштыру) чыгымнарын каплау өчен бүлеп бирелгән акча түбәндәге очракларда эш белән тәэмин итү үзәгенең тиешле таләбен алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә эш белән тәэмин итү үзәгенә кире кайтарылырга тиеш:

эш бирүченең инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урынын җиһазландыру (җайлаштыру) чыгымнары буенча дөрес булмаган мәгълүматлар кертү фактлары ачыкланганда;

җиһазландырылган (җайлаштырылган) эш урынына эш белән тәэмин итү үзәге эшкә урнашу өчен җибәргән инвалид Шартнамәдә күздә тотылган шартларда эш урыны җиһазландырылган (җайлаштырылган) көннән 36 ай эчендә эш белән тәэмин ителмәгәндә;

Шартнамәдә күздә тотылган башка шартлар үтәлмәгәндә.

32. Бу акчаны бу Тәртипнең 31 нче пунктында күрсәтелгән нигезләр буенча кире кайтару вакыты бозылган очракта, эш белән тәэмин итү үзәге бу Тәртипнең 31 нче пунктындагы беренче абзацта билгеләнгән вакыт чыккан көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 7 көн эчендә әлеге акчаны законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына түләттерү чараларын күрә.

Әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджеты керемнә үз ирекләре белән кире кайтарудан баш тартсалар, ул законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелергә тиеш.

33. Эш белән тәэмин ителмәгән инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннарын җиһазландыру (җайлаштыру) чыгымнарын каплау өчен бүлеп бирелгән бюджет акчасыннан максатчан файдалануны һәм эш бирүчеләргә эш белән тәэмин ителмәгән инвалидларны эшкә урнаштыру өчен әлеге чараларга тотылган чыгымнарын каплауны тикшерүдә тоту Министрлык һәм эш белән тәэмин итү үзәкләре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

---